ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 03 2020 г. № 81

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2016 елның 15 мартындагы 74 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2016 елның 15 мартындагы 74 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Регламентның 1.4 пунктына сигезенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 11 декабрендәге 146н номерлы «Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза, адресация объектына адрес бирүдән баш тарту яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар формаларын раслау турында» боерыгы» (алга таба – 146н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 12.02.2015);»;

Регламентның 1.7 пунктында «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча (1 нче кушымта)» сүзләрен «146н номерлы боерык белән билгеләнгән форма буенча» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 2 бүлеген кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

Регламентның 3.5.1 пунктындагы өченче абзацында «2.9 пункты белән» сүзләрен «2.8 пункты белән» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 3.5.4 пунктчасындагы икенче абзацында «бирү турында карар» сүзләреннән соң «(үзгәртү, гамәлдән чыгару)» сүзләрен өстәргә;

Регламентның 3.5.4 пунктының өченче абзацын төшереп калдырырга;

Регламентның 3.5.4 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет җитәкчесенә кул кую өчен карар (күрсәтмә) проектын җибәрү.»;

Регламентның 3.5.5 пунктчасының өченче абзацында, 3.5.6 пунктчасының беренче һәм өченче абзацларында «бирү турында карар (күрсәтмә)» сүзләреннән соң «(үзгәртү, гамәлдән чыгару)» сүзләрен өстәргә;

Регламентның 3.6.1 пунктчасындагы беренче абзацында «Җитәкче» сүзен төшереп калдырырга, «бирү турында» сүзләреннән соң «(үзгәртү, гамәлдән чыгару)» сүзләрен өстәргә;

3.6.1 пунктчасындагы алтынчы абзацында «бирү турында карар (күрсәтмә)» сүзләреннән соң «(үзгәртү, гамәлдән чыгару)» сүзләрен өстәргә;

Регламентның 5 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Идарә хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр Идарәгә, Идарә җитәкчесенең карар һәм гамәленә (гамәл кылмавына) Башкарма комитетка шикаять белдерү хокукына ия.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелә.

Мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.1 һәм 11.2 статьяларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә шикаять белән мөрәҗәгать итә ала.

5.2. Идарәнең, Идарәнең вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, Идарә җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән белешмәләр булырга тиеш. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән төгәлсезлек һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарталар.

5.4. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

5.5. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган Идарә, күпфункцияле үзәк яисә оешма тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә башкарырга кирәк булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән хезмәткәр, вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.»;

Регламентка «Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең блок-схемасы» 1 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН

Җитәкче Д.И. Баландин

Татарстан Республикасы
Түбән Кама шәһәре
башкарма комитетының
2020 елның 25-нче март
81-нче номерлы карарына
кушымта

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яисә таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы | Күчемсез милек объектына адрес бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару | РФ ШтК;<br>РФ ҖК |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-оештыручы органы атамасы | Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре баш-карма комитеты | Устав |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренең тасвирламасы | 1. Күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, гамәлдән чыгару) турында карар (күрсәтмә);<br>2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар | Кагыйдәләрнең 19 п. |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатылу мөмкинлеге Россия | Гариза бирү көнен дә кертеп, 18 көн[1]<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | Кагыйдәләрнең 37 п. |

[1] Административ процедураларның озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибенең тулы исемлеге | а) адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза;<br>б) шәхесне раслаучы документлар;<br>в) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш итсә);<br>г) адресация объектына (объектларына) хокук билгели һәм (яисә) хокук таныклый торган документлар;<br>д) аларның үзгәрүе нәтиҗәсендә бер һәм аннан да күбрәк адресация объекты барлыкка килгән күчемсез милек объектларының кадастр паспортлары (күчемсез милек объектларын бер яки аннан да күбрәк яңа адресация объектлары барлыкка килү белән үзгәртеп корганда);<br>е) адресация объектын төзүгә рөхсәт (төзелә торган адресация объектларына адрес биргәндә) һәм (яки) адресация объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт);<br>ж) адресация объектының кадастр планында яки тиешле территориянең кадастр картасында урнашу схемасы (җир кишәрлегенә адрес бирелгән очракта);<br>з) адресация объектының кадастр паспорты (кадастр исәбенә куелган адресация объектына | Кагыйдәләрнең 34 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | адрес бирелгән очракта);<br>и) җирле үзидарә органының торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү турында карары (аны торак бинадан торак булмаган бинага яки торак булмаган бинадан торак бинага күчерү нәтиҗәсендә, бинага адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару очрагында);<br>к) бер һәм аннан күбрәк яңа адресация объектлары барлыкка килүгә китерә торган бинаны үзгәртеп корганда һәм (яки) яңадан планлаштырганда кабул итү комиссиясе акты (бер һәм аннан күбрәк яңа адресация объекты барлыкка килгән күчемсез милек объектларын (биналарны) үзгәртеп корган очракта);<br>л) исәптән төшерелгән күчемсез милек объекты турында кадастр өземтәсе (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объекты адресын гамәлдән чыгарган очракта);<br>м) күчемсез милек дәүләт кадастрында адресация объекты буенча соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объекты адресы гамәлдән чыгарылган очракта).<br>Гариза биргәндә мөрәҗәгать итүчеләр (мөрәҗәгать итүче вәкилләре), әгәр мондый документлар дәүләт хакимияте органы, җирле | |

| | | |
|---|---|---|
| | үзидарә органы яки дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында оешмаларда булмаса, югарыда күрсәтелгән документларны аңа теркәргә хокуклы.<br>Вәкаләтле органга электрон документлар рәвешендә тапшырыла торган документлар, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тарафыннан раслана.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>тапшыру турында хәбәрнамә һәм теркәлгән документлар исемлеге белән почта аша.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук, мөрәҗәгать итүче тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең | |

| | | |
|---|---|---|
| | бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, шулай ук мөрәҗәгать итүче аларны бирергә хокуклы, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен ачык булган мәгълүматлар);<br>2) Төп характеристикалар һәм күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>3) җирле үзидарә органының торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү турында карары (аны торак бинадан торак булмаган бинага яки торак булмаган бинадан торак бинага күчерү нәтиҗәсендә, бинага адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару очрагында);<br>4) исәптән төшерелгән күчемсез милек объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объекты адресын гамәлдән чыгарган очракта);<br>5) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт кадастрында адресация объекты буенча соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «б» | Кагыйдәләрнең 35 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объекты адресы гамәлдән чыгарылган очракта).<br>Әлеге регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе.<br>Мөрәҗәгать итүчедән җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру;<br>2) Тиешле булмаган органга документлар тапшыру | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>а) адресация объектына адре сбирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать иткән;<br>б) ведомствоара соратуга җавап адресация объ- | Кагыйдәләрнең 40 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | ектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавын күрсәтә, һәм тиешле документ мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган;<br>в) адресация объектына адрес бирү яисә аның адресын гамәлдән чыгару өчен тапшыру гариза бирүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) йөкләнгән документлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртипне бозып бирелгән;<br>г) адресация объектына адресн бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару өчен, Кагыйдәләрнең 5, 8-11 һәм 14-18 пунктларында күрсәтелгән очраклар һәм шартлар юк | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен алына торган дәүләт пошлинасы яисә башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | Кагыйдәләрнең 4 п. |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә, һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Чират булганда, муниципаль хезмәт алуга гариза бирү 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә, шул исәптән электрон формада да соратуны теркәү срогы һәм тәртибе | Гариза кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарына, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату тутыру урыннарына, һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү уры-нына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлек- | |

| | | |
|---|---|---|
| Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләр | ләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15.Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үза-ра хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүма-ти-коммуникацион технологиялардән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) муниципаль хезмәт күрсәтүнең мөмкин-леге яисә мөмкин булмавы, Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында сорату аша мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип) җирле үзи-дарә органының башкару оештыручы органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (комплексны сорату) | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>Идарә бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге Башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>башка затлар белән беррәттән, инвалидларга хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгарга ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмаулары-на) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт күрсәткәндә, консультация, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорату составында муниципаль хезмәт күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча бирелгән булса) һәм электрон формада муниципаль хезмәт | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсендә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алырга мөмкин.<br>Әгәр закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү үзенчәлекләре | каралган булса, гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелә (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә | |